**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«25» ноябрь 2024 ел №52/1

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Җирлек Советының 2019 елның 27 сентябрендәге 50/1 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проектын 1 кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Расларга:

- «Җирлек Советының 2019 елның 27 сентябрендәге 50/1 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 кушымта нигезендә;

- «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибен 3 кушымта нигезендә.

3. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын 2024 елның 16 декаберендә 14 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә дип билгеләргә: ТР, Тукай районы, Әҗмәкәй авылы,_Үзәк ур., 1 йорт.

4. Түбәндәге составта халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссия төзергә:

1) Фазылҗанов М.Г. – комиссия рәисе;
2) Габдрахманова А.Т. – комиссия әгъзасы;
3) Яхин Р.Х. – комиссия әгъзасы.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссиягә халык тыңлауларын үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә халык тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм җирлек Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәйавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 25 нояберендәге 52/1 номерлы карарына 1 кушымта

**«Әҗмәкәйавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Тукай муниципаль районы Әҗмәкәйавыл җирлеге Советы карар проекты**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 24 сентябрендәге 9/1 номерлы Совет карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәйавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1 <u>5 статьяның 1 өлеше 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм тормышка ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

**<u>1.2 5 статьяның 1 өлеше 21 пункты үз көчен югалткан дип танырга;</u>**

**<u>1.3 5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге редакциядәге 21 пунктны өстәргә:</u>**

«21) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

**<u>1.4 6 статьяның 2 өлеше үз көчен югалткан дип танырга;</u>**

**<u>1.5 12 статьяның 3 өлеше 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«Федераль законда билгеләнгән очракларда муниципаль сайлаулар муниципаль сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм уздыруны оештыручы сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.»;

**<u>1.6 19 статьяның 2 абзацы 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«Авыл торак пункты старостасы вәкаләтләре составына әлеге авыл торак пункты керә торган җирлек Советы карары буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясы 10 өлеше 1 - 7 һәм 9_2 пунктларында билгеләнгән очракларда вакытыннан алда туктатыла.»;

**1.7 31 статьяның 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«9. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирлек башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 07 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга тиеш, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.»;

**1.8 31 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 9.1 пунктчасын өстәргә:**

«9.1. Җирлек Советы депутаты «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә күрсәтелгән затларга бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылган очракта азат ителә.»;

**1.9 31 статьяның 10 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«10. Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлек Советы депутаты, җирлек башлыгы, җирле үзидарәнең сайланулы башка вазыйфаи заты тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) карары белән Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.»;

**1.10 31 статьяның 11 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«11. Әлеге статьяның 10 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларның счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактлары ачыкланганда,

Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка башка җаваплылык чарасы куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.»;

<u>**1.11 34 статьяның 1 өлеше 30 пунктын 31 пункт дип санарга һәм түбәндәге эчтәлектәге 30 пунктны өстәргә:**</u>
«30) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү булган муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен әлеге кагыйдәләр нигезендә төзекләндерүне оештыру»;

<u>**1.12 41 статьяның 1 өлеше 11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга, 12 пунктны 11 пункт дип санарга;**</u>

<u>**түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктны өстәргә:**</u>

«12) аларның чит ил агенты статусын алуы;»;

<u>**1.13 44 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 6 өлешне өстәргә:**</u>
«6. Җирлек Башлыгы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне үтәмәгән һәм бурычларны башкармаган өчен җаваплылыктан, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны башкармау «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә күрсәтелгән затларга бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе дип танылган очракта азат ителә.»;

<u>**1.14 50 статьяның 1 пункты 5 өлеше 8 абзацы үз көчен югалткан дип танырга һәм түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:**</u>
«- «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

<u>**1.15 50 статьяның 1 өлеше 6 пункты үз көчен югалткан дип танырга;**</u>

<u>**1.16 50 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацларны өстәргә:**</u>
«- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;
- «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыра.»;

**1.17 VII бүлек һәм 54 статья үз көчләрен югалткан дип танырга, VIII - XV бүлекләрне VII-XIV бүлекләр дип санарга, 55-97 статьяларны 54-96 статьялар дип санарга;**

**1.18 55 статьяның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – җирле үзидарә органы, муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычлар даирәсе белән җирле үзидарә органындагы, әлеге Устав нигезендә төзелә торган комиссиядәге вазыйфа.»;

**1.19 56 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып депутат, җирле үзидарәнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган сайланулы органының хәлиткеч тавыш хокукына ия, комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче әгъзасы тора.
2. Муниципаль хезмәткәр булып федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирлек бюджеты акчалары хисабына түләнә торган акчалата түләү өчен муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча бурычларны үтәүче граждан тора.
3. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник тәэмин итү вазыйфаларын башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләмиләр һәм муниципаль хезмәткәрләр булып тормыйлар.»;

**1.20 57 статьяның 1 өлеше 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«5) билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен, шулай ук җирле үзидарә органы эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны алу;»;

**1.21 57 статьяның 3 өлеше 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«4) җирле үзидарә органында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкцияне, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;»;

**1.22 57 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктны өстәргә:**
«12) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә турында» 2007 елның 2 мартындагы Федераль законның $15^2$ статьясында каралган анкетадагы белешмәләргә аңа билгеле булган үзгәрешләр турында эшкә алучы вәкиленә (эш бирүчегә) язма рәвештә хәбәр итәргә, эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәреш кергән белешмәләрдән тыш (алга таба – анкетадагы белешмәләр).»;

**1.23 74 статьяның 2 өлеше 17 пункты үз көчен югалткан дип танырга;**

**1.24 79 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

### «79 статья. Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы җирлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып тора:

1) тулы текстны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгару; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәү турында таныклык ЭЛ № ФС 77-60244, Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 17.12.2014 бирелгән.
2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районы сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштыру;
3) җирлек территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру: Яңа поселогы (Мәдәният йорты); Әҗмәкәй авылы (авыл мәдәният йорты бинасында); Иске Гәрдәле авылы, (авыл клубы бинасында); Яңа Сарайлы (авыл клубы бинасында).
3. Гражданнарның Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен җирлек Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пункты эшли: Яңа поселогы, Үзәк урамы, 1 йорт.
4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актлардан яки аларның аерым нигезләмәләреннән тыш.
5. Җирлек Советының салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.
6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза куелган көннән үз көченә керә.
7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, челтәр басмаларының исемлеге җирлек Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән җәмәмгатьчелеккә җиткерелә.».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 25 ноябрендәге 52/1 номерлы карарына 2 кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советына язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы формасында түбәндәге үрнәк нигезендә кертелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проектының тексты | Төзәтелгән текст | Төзәтүне исәпкә алып, карар проекты тексты | Төзәтмәләр авторы (фамилиясе,исеме, атасының исеме, адресы, телефоны, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ТР, Тукай районы, Яңа поселок, Үзәк ур., 1 йорт;

почта аша: ТР, Тукай районы, Яңа поселок, Үзәк ур., 1 йорт;

яисә факс буенча 88552378571.

Тәкъдимнәр карар проекты җирлекнең мәгълүмат стендаларынада урнаштырылган көннән 2024 елның 09 декабрнең кадәр эш көннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Тукай районы, Яңа поселок, Үзәк ур., 1 йорт;

почта аша: ТР, Тукай районы, Яңа поселок, Үзәк ур., 1 йорт;

яисә факс буенча: 88552378571.

Гаризалар, халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 2 ноябрендәге 52/1 номерлы карарына кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Әҗмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәйавыл җирлеге Советы карары буенча халык тыңлаулары (алга таба – халык тыңлаулары) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге уставының 20 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Халык тыңлауларында үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советына халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район халкы тора.

3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынган җирлек халкы катнаша ала.

4. Катнашучылар халык тыңлаулары башланырга 30 минут кала теркәлә башлый.

5. Халык тыңлауларында җирлек Башлыгы рәислек итә.

6. Халык тыңлаулары рәислек итүченең катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итүче кереш сүзе белән ачыла.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында халык тыңлаулары секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артмаска тиеш.

11. Халык тыңлауларында катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

12. Халык тыңлауларында катнашучыларның халык тыңлаулары барышына кысылырга, аны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокукы юк.

13. Халык тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау халык тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучылар тарафыннан халык тыңлауларын үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче халык тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне ачыклау өчен, халык тыңлаулары секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре халык тыңлаулары беркетмәсенә кертелә. Беркетмә билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

17. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче төркем тарафыннан әзерләнә.

18. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка игълан ителергә тиеш

19. Халык тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итү авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.